СОВЕТ ПЕЧИЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

18.11.2021　　　　с. Печищи　　　　№ 13-74

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлегенең Печищи авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлеге Печищи авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 6, 7, 8 декабренә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез 2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Печищи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Печищи авыл җирлегенең Печищи торак пунктында Декабристлар, Грузин, Красная Поляна урамнары буенча поселок эчендәге юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ»　　　　　　　　　　«ЮК»

3. Гражданнар җыенын 2021 елның 6 декабрендә Печищи авылы, Декабристлар урамы, 50 нче йорт янында 18.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Гражданнар җыенын 2021 елның 7 декабрендә Печищи авылы, Грузинская урамы, 18 нче йорт янында 18.00 сәгатьтә үткәрергә.

5. Гражданнар җыенын 2021 елның 8 декабрендә Печищи авылы, Красная Поляна урамы, 44 нче йорт янында 18.00 сәгатьтә үткәрергә.

6. Халык җыенын оештыручы итеп Печищи авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә .

7. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы Л.В. Яковлев